# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 6 ноябре №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, ул 2020 елның 6 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, түбәндәге мәсьәләләр буенча: «2021 елда Яшел Үзән муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, I, II төркем инвалидларыннан (ялгыз яшәүче), көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, җирлек территориясендә 3 елдан артык яшәмәүче затлардан тыш, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?:

1. урамнарны яктырту һәм ремонтлау;
2. авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
3. балалар мәйданчыгы төзү (сатып алу, ташу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү)

" РИЗА" "КАРШЫ"

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган халык җыенында катнашучылар исемлегенә 282 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 156 кеше катнашкан, бу 55% тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 156 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре – гамәлдә дип танырга.
2. 2021 елда Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Күгәй авыл җирлегенең Күгәй авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчасын кертергә.
3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:
   1. урамнарны яктырту һәм ремонтлау;
   2. авыл эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
   3. балалар мәйданчыгы төзү (сатып алу, ташу, урнаштыру, килешү буенча эшләр өчен түләү).
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга ( http://pravo.tatarstan.ru ) Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында ( http://zelenodolsk.tatarstan.ru ) шулай ук Күгәй авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында: Күгәй авылы, Үзәк урамы, 29 йорт (администрация бинасы), Күгәй авылы, Үзәк урамы, 32 йорт (мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче Ф. Х. Хисаметдинова